СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

16.01.2020 № 66-298

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-

с. Большие Меми

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 41-202нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Югары Ослан прокурорының 2019 елның 25 декабрендәге 02-07-02 номерлы протестын карап, Россия Федерациясе Салым кодексының 406нчы маддәсе нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 41-202нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә төзелеш корылмалар»;

1.2. 2 пунктның 2 пунктчасында «фатирлар» сүзләреннән соң «фатир өлешләре» сүзләрен өстәргә, «бүлмәләр» сүзеннән соң «бүлмәләрнең бер өлеше» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 пунктның 3 пунктчасында «торак йортлар» сүзеннән соң «торак йортларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарның яңа редакциясен расларга (1нче кушымта)

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина

Олы Меми авыл җирлеге Советының
2020 елның 16 гыйнварындагы
66-298нче номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге территориядә физик затлар милкенә салым турында

1. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләнергә тиешле салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гаражлар һәм машина-урын;

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелшкә карата»;

2) 0,2 процент:

Фатир, фатирларның бер өлеше;

бүлмә, бүлмәләрнең бер өлешенә карата;

3) 0,3 процент:

торак йортлар, торак йортларның бер өлеше;

әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплексларга карата;

4) 2 процент:

аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

5) 0,5 процент башка салым салу объектларына карата;

6) 2015 елда – 1,5 процент, 2016 елда-1,8 процент, 2017 елда-2 процент, алдагы елларда-Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.

3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатир милекчеләренә ташламаны әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясенең процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
башлыгы Г. А. Фомина